КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 март г.Казань № 200

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибен расларга.

2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган махсуслаштырылган оешма торак урыннар бирү буенча вәкаләтле оешма булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга бирү өчен билгеләнгән торак урыннар махсус-

лаштырылган оешманың попечительләр советы тарафыннан килештерелгән күләмдә бүленә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 март, 200 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга социаль ипотека системасында торак урыннар бирү юлы белән торак урыннар бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктлары – Татарстан Республикасында билгеләнгән административ-территориаль бүленеш нигезендә яши торган кешеләр санына карамастан авыл торак пунктларына кертелгән Татарстан Республикасындагы поселоклар, авыллар һәм башка авыл торак пунктлары;

махсуслаштырылган оешма – «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә аны турыдан-туры тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан төзелгән яки вәкаләт бирелгән коммерциягә карамаган республика оешмасы яки органы;

гариза бирүче – Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую максаты белән, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы һәм гаилә әгъзасы булган гаилә исеменнән (яисә, әгәр никахлашмаган булса, үз исеменнән) гариза бирүче Россия Федерациясе гражданы;

гариза бирүченең гаилә әгъзалары – аның белән бергә яшәүче балалары һәм ире (хатыны), әгәр гариза бирүче тарафыннан башка туганнары һәм тәрбиягә алынган эшкә яраксыз затлар үз гаиләсе буларак йортка кертелгән булса, алар гариза бирүченең гаилә әгъзалары дип танылырга мөмкин;

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую нормасы – торак хокуклары объектларында торак сайлап алу урыны буенча авыл торак пункты территориясендә гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган гомуми мәйдан күләме;

алдан туплана торган акча – гариза бирүче тарафыннан өстенлекле рәвештә торак урын сайлап алу хокукында өлешләп түләнә торган торак урын сатып алу максаты белән төзелеш объектын файдалануга тапшырганга кадәр туплана торган

акча. Алдан акча туплау тәртибе – ирекле һәм ул гариза бирүче тарафыннан фатир сайлап алуның өстенлекле хокукыннан файдалану нияте, шулай ук, алдан туплана торган акчаны махсуслаштырылган оешманың исәп-хисап счетына кертү шарты белән, ай саен түләнә торган түләүләрне өлешләп түләү срогын арттыру мөмкинлеге булуыннан чыгып билгеләнә.

башлангыч кертем – социаль ипотека шартнамәсе (алга таба – шартнамә) төзелә торган вакытта гариза бирүче тарафыннан кертелә торган, катнашучының торак урын сатып алу хокукын тәэмин итә торган акча.

3. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую нормасы гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйданның кимендә 18 квадрат метры күләмендә билгеләнә.

4. Торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган гомуми мәйданның күләмен исәпләп чыгарганда, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча авыл торак пункты территориясендә гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының үз милкендәге һәм (яки) наем шартнамәсе буенча барлык файдаланудагы торак урыннары (алардагы өлешләре), шулай ук мондый урын милекчесе тарафыннан гаилә әгъзаларына, аларны үз гаилә әгъзасы буларак йортка кертү юлы белән, даими яшәү хокукы бирелгән торак урын исәпкә алына; шул ук вакытта әлеге торак урыннарның бергә кушып исәпләнгән гомуми мәйданы күләме бу торак урыннардан файдаланучы гаиләнең барлык әгъзалары (торак урын милекчесен кертеп) санына, аларның бергә яшәү (теркәлү) фактына карамыйча, пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарылырга тиеш.

5. Гаризада күрсәтелгән гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының торак хокуклары объектлары турындагы мәгълүматлар җирле үзидарә органы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә тикшерелә. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында һәм җирле үзидарә органнарының эш итү карамагында торак хокуклары объектлары турында мәгълүматлар булмаганда, гариза бирүче үзенең, аның гаилә әгъзаларының күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документларны (торак урынга милек хокукы турында таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе һ.б.) яки аларның нотариаль таныкланган күчермәләрен тапшыра.

6. Гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән гаилә әгъзаларының, торак урында яшәүче башка гражданның яшәү (булу) урыны турындагы мәгълүматларны һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы мәгълүматларны тикшерү максатларында җирле үзидарә органы, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, Россия Федерациясе чикләрендә гариза бирүченең булу урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне исәпкә алуның база дәүләт мәгълүмат ресурсына һәм Граждан хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрына электрон документ формасында ведомствоара рәсми сораулар җибәрә. Әлеге мәгълүматлар алынганнан соң, җирле үзидарә органы аларны тикшереп чыга.

7. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга

мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую түбәндәге шартлар үтәлгәндә гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче хезмәт эшчәнлеген Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмада гамәлгә ашыру;

гаиләнең бер әгъзасына кушу нәтиҗәсендә килеп чыккан яшәү минимумын тәэмин итә һәм торак урыннарны милеккә сатып алу буенча ай саен түләнә торган агымдагы түләүләрне үз вакытында каплауны гарантияли торган айлык җыелма керем булу;

торак сайлап алу урыны буенча авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең гомуми дәрәҗәсе бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән исәпкә алу нормасыннан ким булмау;

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүнең федераль һәм республика программалары буенча махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә элек сатып алынган торак урынның кыйммәте өчен түләү йөкләмәләре булмау, шул исәптән аңа түләү өчен махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамә нигезендә алынган максатчан акчалата заем тулысынча кире кайтарылу.

8. Гариза бирүче, бу Тәртипнең 3 нче кушымтасындагы исемлек буенча гариза бирүче тарафыннан бирелергә тиешле документларны теркәп, бу Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы форма буенча гариза тапшыра һәм, барлык кирәкле мәгълүматларны күрсәтеп, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча гариза бирүче анкетасын тутыра.

Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен гариза бирүчедән гаризалар кабул итү түбәндәгечә башкарыла:

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (КФҮ) тарафыннан;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы аша.

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую турындагы гаризаларын карап тикшерү җирле үзидарә органнары тарафыннан гариза бирелгән көннән 30 көннән дә артмаган срокта гамәлгә ашырыла. Гариза бирүчегә, документлар исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, аларның алынуы турында хәбәр ителә.

9. Җирле үзидарә органнары исәпкә алу делосын формалаштыра, иҗтимагый торак комиссиясендә гариза бирүчеләрнең гаризаларын карап тикшерә һәм Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую турында йә исәпкә куюдан баш тарту турында карар чыгара.

Түбәндәге очракларда гариза бирүчене исәпкә куюдан баш тартыла:

бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую хокукын расламый торган документлар һәм мәгълүматлар алынганда;

бу Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар булмаганда яки алар тулысынча тутырылмаганда;

гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыкланганда;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булганда;

махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүнең федераль һәм республика программалары буенча элек сатып алынган торак урынның кыйммәте өчен тулысынча түләнмәгәндә, шул исәптән аңа түләү өчен махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамә нигезендә алынган максатчан акчалата заем тулысынча кире кайтарылмаганда.

Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую турында йә исәпкә куюдан баш тарту турында карарлар бу Тәртипнең 6 һәм 7 нче кушымталарындагы форма буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган боерык рәвешендә кабул ителә.

Исәпкә алу делосын теркәү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенең гариза бирүчегә уникаль исәпкә алу коды бирелә торган боерыгы нигез булып тора.

Җирле үзидарә органы җитәкчесенең исәпкә алу делосын теркәү турындагы боерыгы күчермәсен, билгеләнгән форма буенча тутырылган, расланган гаиләнең исәпкә алу карточкасын, гариза бирүче анкетасын теркәп, җирле үзидарә органнары исәпкә куелган көннән 30 көн эчендә махсуслаштырылган оешмага җибәрә. Әлеге документларны тапшыру документ төрендәге кәгазьдә һәм (яки) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарның локаль исемлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан алып барыла һәм даими нигездә актуаль хәлдә (шул исәптән исемлекләрдән төшереп калдыру) тотыла.

11. Махсуслаштырылган оешма җирле үзидарә органнарыннан Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнар исемлеген, шулай ук бу Тәртипнең 9 пунктындагы унынчы абзацында күрсәтелгән документларны кабул итә һәм әлеге документлар кабул ителгән көннән 15 көн эчендә гариза бирүчеләрне махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында карар кабул итә яки тәкъдим ителгән, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Законны үтәү йөзеннән кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый

актлары таләпләренә туры килми торган гариза бирүчеләр исемлеген, сәбәпләрен күрсәтеп, җирле үзидарә органнарына кире кайтара.

Махсуслаштырылган оешма тарафыннан документларның кире кайтарылуы җирле үзидарә органнары өчен гариза бирүчене социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы буларак исәптән төшерүгә нигез була. Бу турыда гариза бирүчегә карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә, исәптән төшерелү сәбәбе аңлатылып, гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр ителә.

Башлангыч исемлек бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан боерык кабул ителгән дата буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары яктылыгында төзелә.

Махсуслаштырылган оешма магистраль һәм квартал эчендәге челтәрләр белән тәэмин ителгән, аңа күпләп йортлар салу өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә торак төзелешенең фаразлана торган күләме чикләрендә ай саен башлангыч исемлеккә кертелгән гаиләләрне махсуслаштырылган оешма реестрына чират белән кертү турында карар кабул итә. Әлеге карар махсуслаштырылган оешма реестрына элек кертелгән гражданнарны исәпкә алып кабул ителә.

12. Махсуслаштырылган оешма реестры Татарстан Республикасы муниципаль районнары яктылыгында төзелә.

13. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хокукы махсуслаштырылган оешма реестрына гаиләләр кертелгән көннән барлыкка килә, бу турыда махсуслаштырылган оешма гариза бирүчегә махсуслаштырылган оешма реестрына гаиләләр кертелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә язмача хәбәр итә, анда бу хәбәрнамә алынган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән социаль ипотека шартнамәсен төзү кирәклеген күрсәтә.

14. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту хокукы барлыкка килү вакытыннан алып, махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алынган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән социаль ипотека шартнамәсен төзү һәм чираттагы елга «Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү» программасы тормышка ашырыла торган ел алдындагы елның IV кварталына Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар кыйммәте күләменнән кимендә 11 процент күләмендә алдан туплана торган акча өчен ай саен түләүләр гамәлгә ашыру йөкләмәсе барлыкка килә.

15. Гаризада һәм документларда күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар әлеге үзгәрешләр үз көченә кергән көннән 30 көн эчендә алар турында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучыларны исәпкә кую урыны буенча җирле үзидарә органнарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

16. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга

мохтаҗ булучы гражданнар торак урын сайлап алу гамәлгә ашырыла торган календарь елда һәм торак урынны сайлап алу беркетмәсенә кул куелганга кадәр Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую урыны буенча җирле үзидарә органнарында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә хокукын раслау максатларында яңадан теркәлергә тиеш.

Яңадан теркәлү Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарны исәпкә кую тәртибендә кебек гамәлгә ашырыла.

Әгәр Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнар исәпкә куелган датадан соң бер ел эчендә торак урын сайлап алсалар, яңадан теркәлү таләп ителми.

17. Гариза бирүченең махсуслаштырылган оешма реестрында тору хокукы гаилә тарафыннан торак урын сайлап алынганга кадәр, түбәндәге очраклардан тыш, саклана:

гаризада һәм исәпкә алырга нигез булган, тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыкланганда;

исәпкә куелганда вазыйфаи затларның хокуксыз гамәлләр кылу очраклары ачыкланганда;

Татарстан Республикасындагы торак урынны сайлап алу урыны буенча авыл торак пунктында хезмәт эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар ачыкланганда;

аның тарафыннан бу Тәртипнең 7 пунктында каралган нигезләр югалтылганда;

бу Тәртипнең 8 нче кушымтасындагы форма буенча исәптән төшерү турында гариза бирелгәндә;

яңадан теркәлү барышында Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданның социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә хокукын расламый торган мәгълүматлар ачыкланганда;

гариза бирүче тарафыннан махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алынган көннән 90 көн эчендә социаль ипотека шартнамәсе төзелмәгәндә;

ай саен түләнә торган түләүләрне башкару буенча шартнамә шартлары алты айдан артык үтәлмәгәндә;

якларның килешүе буенча шартнамә өзелүгә бәйле рәвештә, махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдырылганда.

Бу пунктта күрсәтелгән очраклар ачыкланганда, җирле үзидарә органнары бу турыда мондый очрак билгеле булган көннән 10 көн эчендә махсус оешмага хәбәр итә.

Махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдыру махсуслаштырылган оешманың карары белән гамәлгә ашырыла; ул карар кабул ителгән көннән

10 көн эчендә җирле үзидарәнең тиешле органы тарафыннан, төшереп калдыруның сәбәбе күрсәтелеп, язма рәвештә мәҗбүри хәбәр ителә.

Махсуслаштырылган оешма хәбәрнамәсе алынганнан соң, җирле үзидарә органы тиешле хәбәрнамә алынган көннән 10 көн эчендә гариза бирүчене исәптән төшерү турында карар кабул итә.

18. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга социаль ипотека буенча торак төзелешенә бүлеп бирелә торган махсуслаштырылган оешма акчасы исәбеннән төзелгән торак йортлардан торак урыннарны гражданнар категорияләре буенча бүлү ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган квоталар нигезендә гамәлгә ашырыла.

19. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннарның гомуми мәйданы нормативлары:

кеше саны өчкә кадәр булган гаилә өчен – 54 квадрат метр;

кеше саны дүрт һәм аннан күбрәк булган гаилә өчен – бер кешегә 18 әр квадрат метр.

20. Әгәр Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның исәпкә куелганнан соң баласы туса, шулай ук һәр бала уллыкка (кызлыкка) алынганда, аларның 200 мең сум күләмендә, әмма торак урынның түләнеп бетмәгән өлеше кыйммәтеннән яки бала туган, шулай ук һәр бала уллыкка (кызлыкка) алынган вакытка төп бурычның түләнеп бетмәгән суммасының калган өлешеннән артмаган күләмдә торак урынның кыйммәтенә түләү өчен җибәрелә торган дәүләт ярдәменә хокукы барлыкка килә.

21. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар бары исәпкә куелу урыны буенча торак урын сайлап алу хокукына ия.

22. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарга торак урын бирү конкурс нәтиҗәләре буенча торак урынны сайлап алуда катнашу тәртибендә гамәлгә ашырыла.

23. Конкурста Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган, шартнамә төзегән һәм бу Тәртипнең 20 пунктында билгеләнгән нормативлар нигезендә бирелә торган торак урынның кыйммәтеннән кимендә 10 процент башлангыч кертем туплаган гражданнарга катнашырга рөхсәт ителә.

24. Торак урынны сайлап алу конкурсы Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның билгеләнгән квоталар чикләрендә үзләренең булачак торак урыннарын билгеләү максатларында уздырыла.

25. Конкурста катнашу өчен Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар шартнамәдә күрсәтелгән индивидуаль номер һәм пароль буенча махсуслаштырылган оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) электрон рәвештә заявка тутыра.

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар тарафыннан заявкада сайлап алына торган торак урыннарның тели торган исемлеге өстенлек кимү тәртибендә күрсәтелә. Заявка рәсми сайтта теркәлә.

26. Электрон рәвештә билгеләнә торган иң зур рейтингка ия гариза бирүче конкурста җиңүче дип танила.

27. Рейтинг Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарның алдан тупланган акчасына (мең сумда) тигез булган, аларның махсуслаштырылган оешма счетында булу көненә (конкурска йомгаклар ясалган көнгә кадәр соңгы 10 көнне кертмичә) тапкырланган сан күрсәткече буларак билгеләнә.

28. Махсуслаштырылган оешманың конкурста җиңүчеләрне билгеләү турындагы карары конкурс йомгаклары турындагы хисапта рәсмиләштерелә. Мәгълүмат рәсми сайттагы шәхси биттә чагылыш таба.

29. Конкурс йомгаклары турында хисап расланган көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар торак урынны сайлап алу буенча башлангыч беркетмәгә кул куя.

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар тарафыннан торак шартларын яхшыртуга хокукы раслану һәм торак йортны файдалануга тапшыру шарты белән махсуслаштырылган оешманың попечительләр советы тарафыннан расланган форма буенча торак урынны сайлап алу беркетмәсе рәсмиләштерелә. Торак урынны сайлап алу беркетмәсе шартнамәнең аерылгысыз бер өлеше булып тора һәм конкурста җиңүченең сайлап алынган торак урынга урнашу һәм аннан файдалану хокукын раслый.

Торак урынны сайлап алу беркетмәсенә Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар тарафыннан сайлап алынган торак урын урнашкан торак йорт файдалануга тапшырылган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча кул куела.

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар тарафыннан конкурс йомгаклары турында хисап расланган көннән 30 көн эчендә торак урын сайлап алу беркетмәсенә кул куелмаган очракта, Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы граждан тарафыннан торак урын сайлап алу конкурсы йомгаклары һәм торак урын сайлап алуның башлангыч беркетмәсе гамәлдән чыгарыла.

Объектны файдалануга тапшыру датасы һәм сайлап алынган торак урынга урнашу мөмкинлеге турында мәгълүмат махсуслаштырылган оешма тарафыннан рәсми сайтта объект файдалануга тапшырылган көннән 10 көн эчендә урнаштырыла.

30. Сатып алына торган торак урынның бер квадрат метрының башлангыч кыйммәте махсуслаштырылган оешма тарафыннан билгеләнә. Торак урынның түләнмәгән өлеше өчен кыйммәте кабул итү комиссиясе тарафыннан төзелеп беткән объектны кабул итү акты расланган көннән ай саен елына 7 процент (айга 7/12 процент) исәбеннән чыгып арта бара.

Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы төшкән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты торак урынның түләнмәгән өлеше өчен кыйммәтенә керә торган еллык ставкаларны (процентларны) киметү мөмкинлеге мәсьәләсен карый.

31. Торак урынны милеккә сатып алу буенча ай саен түләнә торган агымдагы түләүләрне өлешләп түләү 28,5 елга кадәр тәшкил итә.

32. Торак урыннарны милеккә сатып алу буенча өлешләп түләүгә бирелгән, ай саен түләнә торган агымдагы түләүләр торак урынны сайлап алу беркетмәсе рәсмиләштерелгән вакытта торак урынның сатып алынмаган мәйданына тапкырланган һәм айлар буенча өлешләп түләү срогына бүленгән торак урынның бер квадрат метры кыйммәтеннән чыгып исәпләнә.

33. Гариза бирүче торак урынны сайлап алу беркетмәсен рәсмиләштергән вакыттан торак урынның гомуми мәйданының түләнмәгән өлеше өчен наем түли.

34. Гариза бирүче махсуслаштырылган оешма белән төзелгән социаль ипотека шартнамәсе буенча сатып алынган торак урын кыйммәтен тулысынча түләп бетергәннән соң, гаилә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән төшерелергә тиеш.

35. Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар социаль ипотека шартнамәсе буенча бурычның калган өлешен, махсуслаштырылган оешма белән сайлап алынган торак урынны сатып алу-алу турында шартнамә төзеп, кредит оешмаларының заем акчасы исәбеннән түләп бетерергә хокуклы, шул ук вакытта социаль ипотека шартнамәсе буенча моңа кадәр тупланган акча һәм дәүләт ярдәме буларак түләүләр сатып алу-сату шартнамәсе буенча башлангыч кертем буларак күчерелә.

36. Җирле үзидарә органнары һәм махсуслаштырылган оешма карарларына, аларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

______________________________________________________
(район, шәһәр исеме)
җирле үзидарә органы җитәкчесе ____________________ ка
гр ____________________________________________ тан (нан),
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (тулысынча)
______________________________________________________
(көне, ае, елы)
______________________________________________________
(шәһәрдә, поселокта, авылда түбәндәге адрес буенча яшәүче)
______________________________________________________
(почта индексы, тулы адресы, элемтәгә керү өчен телефоны)
______________________________________________________
______________________________________________________
______________________________________________________

ГАРИЗА

________________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булу сәбәпләрен,
________________________________________________________________________________
гаиләнең бер әгъзасына социаль ипотека буенча исәпкә кую нормасыннан түбән булган торак мәйдан белән
________________________________________________________________________________
тәэмин ителешне, санитария һәм техник таләпләргә туры килми торган торак урында яшәүне,
________________________________________________________________________________
коммуналь фатирда яшәүне, биләнә торган урыннарны сүтү кирәклеген күрсәтергә)
________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________
(биләнә торган торак хокуклары объектының төрен күрсәтергә:
________________________________________________________________________________
изоляцияләнгән (коммуналь), бүлмәләр саны)
________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________
бәйле рәвештә, Сездән мине социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен ____ кеше составындагы гаилә белән исәпкә алуыгызны сорыйм.

Билгеләнгән форма буенча язылган, гариза белән бергә бирелә торган, социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен минем гаиләмне исәпкә алуга кирәкле мәгълүматлар бирелгән анкета теркәлә.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны, аларның рәсми сорауларына, шулай ук махсуслаштырылган оешма тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле документларны тикшерүгә ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә бер ай эчендә алар турында исәпкә алу урыны буенча җирле үзидарә органнарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш дип кисәтелде.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгәннәргә туры килми торган мәгълүматлар ачыкланган очракта, безне закон белән билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерәчәкләр.

Моның белән мин тиешле салым органнарында һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу органнарында минем керемнәрем һәм милек хокукында минеке булган мөлкәт турындагы мәгълүматларны тикшерергә ризалык бирәм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аларны өченче затларга тапшыруга ризалык бирәбез.

Гаризаны карау нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйбыз:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталының шәхси кабинеты аша электрон төрдә;

☐ күпфункцияле үзәктә.

Гариза бирүче ______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча, имзасы)

Гаиләнең
эшкә сәләтле әгъзалары: 1.____________________________________________________
2.____________________________________________________
3.____________________________________________________
4.____________________________________________________

(гаиләнең барлык эшкә сәләтле әгъзаларының имзалары)

20___ ел, «___» __________
(дата сүз белән)

Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

## Гариза бирүче анкетасы

1. Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме* ________________________________________
(тулысынча)

2. Түбәндәге адрес буенча яшим _____________________________________________
(район, торак пункт, урам, йорт, фатир, бүлмә)

_____________________________________________

_____________________________________________

_____________________________________________
(элемтәгә керү телефонын күрсәтергә: өй, эш)

3. Шәхесне таныклый торган документ _____________________________________________
(документ төре)

сериясе ___________ номеры ___________________________ кем һәм кайчан биргән ____________________

4. Туган көне _____________________________________________
(көне, ае, елы)

5. Туган урыны _____________________________________________

6. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры |_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|_|
(ИНН – барлык унике билгене күрсәтергә)

7. Эш урыны _____________________________________________
(әгәр гариза бирүче эшләмәсә, эш белән тәэмин ителмәүнең сәбәбен күрсәтергә)

_____________________________________________
(оешманың, бүлекнең тулы исемен, вазыйфасын күрсәтергә)

_____________________________________________

_____________________________________________

_____________________________________________

8. Гаилә составы ________ кеше.

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме* тулысынча | Туганлык мөнәсәбәт-ләре** | Туган көне | Шәхес таныклыгы (сериясе, номеры) | ИНН | Эш, уку урыны | Гариза бирүче-нең эш стажы | Оешманың ИННы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | 01 | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |

* Атасының исеме булганда күрсәтелә.
** Татарстан Республикасындагы авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булучы гражданнарга торак урыннар бирү тәртибенә 5 нче кушымтаның 2.6 пунктында күрсәтелгән кодлар буенча.
*** Эш стажы түбәндәге рәвештә күрсәтелә: мәсәлән, 20/01/14, монда 20 – гомуми эш стажы, 01 – соңгы эш урыны буенча эш стажы, 14 – бюджет өлкәсендә гомуми стаж; балаларның эш стажы түбәндәге рәвештә күрсәтелә: 00/00/00.

9. Оешманың ИННы ____________________________________

___________________________________________________________

(әгәр гариза бирүче эшләмәсә, ИНН күрсәткечендә нуль куела, ягъни эшләмәүче зат өчен ИНН – 0 000 000 000)

10. Соңгы эш урында стаж тәшкил итә ____________________________________________

(ел санын күрсәтергә)

11. Гомуми эш стажы тәшкил итә ________________________________________________

(ел санын күрсәтергә)

12. Мин һәм минем белән яшәүче гаилә әгъзалары торак мәйданын (өлешен) милек хокукында билибез ________________________________________________________________

(нинди, кем, кайда, нигезләрен күрсәтергә)

___________________________________________________________

___________________________________________________________

13. Наем шартнамәсе буенча ____________________________________________

(төгәл кем икәнен күрсәтергә)

___________________________________________________________

| Т/с | Гариза бирүче һәм гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме* | Туганлык мөнәсәбәтләре | Язылу датасы | Аерым финанс-шәхси счет булу | Мәйданы (гомуми/торак) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |

14. Милек хокукында ________________________________________________

(төгәл кем икәнен күрсәтергә)

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме* (тулысынча) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Адресы | Мәйданы (гомуми/торак) | Милек турында таныклык буенча теркәлү датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |

15. Гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе ____________

___________________________________________________________

(гаиләнең бер әгъзасына күпме туры килә торган кв.метрны күрсәтергә)

16. Били торган торак урынның тибы ____________________________________________

(торак урынның тибын күрсәтергә: индивидуаль торак йорт,

___________________________________________________________

блоклы итеп салынган йорт, коммуналь фатир, фатир, бүлмәләр саны)

___________________________________________________________

(төзелеш стандартын күрсәтергә)

___________________________________________________________

17. Теләсә нинди кертемнәр өчен банкларның һәм башка оешмаларның кредит акчасыннан файдалану

(фатир, техника сатып алу, уку өчен түләү һ.б.) (әйе – 1, юк – 2)

18. Ай саен түләүләр суммасы ________________________________________________
(түләүләрнең конкрет суммасын күрсәтергә)
_____________________________________________________________________

19. Түләүләр срогы тәмамлану ________________________________________________

20. Тутырылган декларация нигезендә бер кешегә гаиләдә ай саен җыелма керем тәшкил итә ______
_____________________________________________________________________
21. Башлангыч кертемне кертү (пай туплау) мөмкинлеге ____________________________
(әгәр мөмкинлек булса,
_____________________________________________________________________
(күпме процент икәнен күрсәтергә: 10%, 20%, 30%, 30 проценттан артык)
_____________________________________________________________________

22. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның квоталар категориясе ____________
(гариза бирүченең
_____________________________________________________________________
кайсы гражданнар категориясенә каравын күрсәтергә: бюджет өлкәсе хезмәткәре/
_____________________________________________________________________
оешма хезмәткәре/башкалар)

23. Торак урынның таләп ителә торган (теләгән) төре ______________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Бу анкетадагы мәгълүматларның түбәндә күрсәтелгән датага дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аларны өченче затларга тапшыруга ризалык бирәбез.

